**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЧУЛПАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**«20» май 2022 ел** **№ 39**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Советының 2021 елның 28 июлендәге 20 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2008 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Чулпан авыл җирлеге Уставы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Нигезләмәнең 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Советының 2021 елның 28 июлендәге 20 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«4.2. Чулпан авыл җирлеге территориясендә агач һәм куаклар кисү Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан комиссия тикшерүе акты нигезендә бирелә торган рөхсәт нигезендә 17 эш көне эчендә башкарыла».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Советының Сәламәтлек саклау, санитар һәм экологик эш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Чулпан авыл җирлеге
Советы рәисе Ф.Ф. Зыятдинов